ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**19.05.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 870**

Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы Зеленодольск муниципаль районы физик культура спорт оешмалары хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә акчалата түләүләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физик культура спорт оешмалары хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә акчалата түләүләр билгеләү турында» 2009 елның 31 октябрендәге 979 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Расларга:

- Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы Зеленодольск муниципаль районының физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән акчалата түләүләр бирү тәртибен (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының социаль мәсьәләләр буенча җитәкчесе урынбасарына Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче Зеленодольск муниципаль районы физик культура спорт оешмаларына җиткерергә

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Зеленодольск Республикасы Башкарма комитетының социаль мәсьәләләр буенча җитәкче урынбасарына йөкләргә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуын 01.01.2020 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

5. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы Р.З. Хаҗиевка әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Җитәкче М.П. Афанасьев

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма
комитеты карарына карата 1 нче кушымта
19.05.2020 №870

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СПОРТ РЕЗЕРВЫН ӘЗЕРЛӘҮНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ФИЗИК КУЛЬТУРА СПОРТ ОЕШМАЛАРЫНДА ЭШЛӘҮЧЕ ЯШЬ БЕЛГЕЧЛӘРГӘ АКЧАЛАТА ТҮЛӘҮЛӘР БИРҮ ТӘРТИБЕ

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы Зеленодольск муниципаль районының физик культура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә түбәндәге акчалата түләүләр бирү тәртибен һәм шартларын билгели:

эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә 1111 сум күләмендә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү, әмма аена 1111 сумнан да артык түгел;

хуҗалык төзекләндерүгә бер тапкыр бирелә торган 20 000 сум күләмендә акчалата түләү

2. Оешмалар хезмәткәрләренә-яшь белгечләргә акчалата түләүләр спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физик культура спорт оешмалары хезмәткәрләренә-яшь белгечләренә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүне гамәлгә ашыруга Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар хисабына башкарыла.

3. Оешма хезмәткәре - яшь белгеч дип 30 яшькә кадәрге (30 яшьне дә кертеп) Россия Федерациясе гражданы танылa, көндезге формада һөнәри белем бирү оешмасын, югары белем бирү оешмасын югары белем бирү программалары - бакалавриат, специалитет, магистратура программалары буенча дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирү оешмасын (алга таба - һөнәри белем бирү оешмасы яки югары белем бирү мәгариф оешмасы) беренче тапкыр тәмамлаган, һәм һөнәри белем бирү оешмасын яисә югары белем бирү оешмасын тәмамлаган елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча һөнәри белем дәрәҗәсе һәм квалификациясе нигезендә хезмәт килешүе буенча түбәндәге вазифаларга оешмага эшкә алынган: физкультура буенча инструктор, педагог-оештыручы, педагог-психолог, җайлаштырылган физик культура буенча инструктор-методист, җайлаштырылган физик культура буенча өлкән инструктор-методист, тренер, җайлаштырылган физик культура буенча тренер-укытучы, хореограф, тренировкалар процессы администраторы, җайлаштырылган физик культура буенча өлкән тренер-укытучы.

4. Ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү хезмәткәр - яшь белгечләргә аны эшкә урнаштыру аеннан соң килгән айның 1 числосыннан билгеләнә һәм әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган вазыйфада өзлексез эшләү шарты белән аны билгеләү датасыннан соң өч ел дәвамында түләнә.

Яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүне билгеләү, туктату, озайту турындагы карар оешма боерыгы белән раслана.

Хезмәткәр-яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү вакыты түбәндәге очракларда дәвам итә:

Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә чакырылыш буенча хезмәт итү яки альтернатив граждан хезмәте;

йөклелек һәм бала табу буенча ял вакытында, балага өч яшь тулганчы;

көндезге формада аспирантурада уку вакытына.

5. Хезмәткәр-яшь белгеч, әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган вазыйфага башка оешмага күчкәндә, 30 көннән дә артмаган вакытка эштән туктап тору рөхсәт ителә.

6. Хезмәткәр - яшь белгеч штат саны кимүгә бәйле рәвештә яки штат кыскару сәбәпле эштән киткәндә һәм алга таба әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган вазыйфага башка оешмага эшкә урнашканда, 60 көннән дә ким булмаган вакытка ял итү рөхсәт ителә.

7. Яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү яшь белгечнең төп эш урыны буенча гына билгеләнә.

8. Эшче-яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү төп вазыйфа буенча һәм эш әлеге хезмәткәр - яшь белгеч тарафыннан эчке берләшү шартларында башкарылганда билгеләнә, ләкин 1 ставкадан да артмый.

9.Эшче-яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$D = P \times \frac{H_f}{H_n},$$

биредә:

D - хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү күләме, сум;

P - яшь белгечләргә аена 1 111 сум күләмендә стимуллаштыручы өстәмә түләү;

Hf - хезмәткәр-яшь белгеч тарафыннан эшләнгән сәгатьләрнең факттагы саны, сәгать;

Hn-спорт резервын әзерләүне оештыру хезмәткәрләренең хезмәт хакының база ставкасы, сәгать нормасы.

10. Хуҗалык төзекләндерүгә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү , хезмәткәргә бер тапкыр башкарыла.

11. Хезмәткәр, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы раслаган форма буенча, оешма җитәкчесе исеменә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү турында гариза белән һөнәри белем бирү оешмасын яки югары белем бирү оешмасын тәмамланганнан соң, эшкә урнашкан оешмада ике ел дәвамында мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

12. Хуҗалык төзекләндерүенә бер мәртәбә акчалата түләү алу шарты булып хезмәткәрнең һөнәри белем бирү оешмасы яки югары белем бирү мәгариф оешмасы тәмамлаганнан соң, эшкә урнашкан оешмада ике ел дәвамында төп эш урыны буенча эшләү йөкләмәсе тора.

Хезмәт килешүе туктатылган очракта, аны эшкә алган көннән соң ике ел вакыт үткәнчегә кадәр ул әлеге срок тәмамланганчы фактта эшләнмәгән вакытка пропорциональ рәвештә билгеләнгән күләмдә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү өлешен кире кайтарырга тиеш.

13. Оешмалар ай саен, агымдагы елның 3 числосына кадәр, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлегенә түбәндәге документлар тапшыралар:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга акча бирү турында гариза;

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча оешма хезмәткәрләре-яшь белгечләренең реестрлары.

14. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлеге әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән документларны карый һәм ай саен, агымдагы елның 5 числосыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына бюджетара трансфертлар бирү өчен реестр һәм гариза тапшыра.

Оешма әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган пакетын яки югарыда аталган пункт таләпләренә туры килми торган документларны тапшырган очракта, спорт бүлеге гаризаны кире кайтара һәм биш көн эчендә оешмага, кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, хәбәр итә.

Гаризаны кире кайтару турында хәбәрнамә алган көннән алып, әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән, әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән документларны кабат тапшыра.

15. Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләрне башкару өчен оешма чыгымнарын финанс белән тәэмин итү күрсәтелгән максатларга оешмага субсидияләр бирү юлы белән гамәлгә ашырыла. Субсидия, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 781 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты һәм оешма арасында төзелгән килешү нигезендә, муниципаль бюджет яисә автоном учреждениегә субсидияләр бирү турындагы килешүнең типлаштырылган формасы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан бирелә.

16. Татарстан Республикасы бюджетыннан, «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль унитар предприятиесе, әлеге максатларга бюджетара трансфертлар кергән саен, казначылык органнарында ачылган оешмаларның шәхси счетларына эшләүче хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акча түләүләрен гамәлгә ашыру өчен субсидияләр күчерә.

17. Оешмалар Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлегенә  хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акча түләүгә субсидия куллану турында хисап тапшыралар.

18. Агымдагы финанс елында оешма тарафыннан кулланылмаган субсидияләр күләме, Татарстан Республикасы бюджетына билгеләнгән тәртиптә кире кайтару өчен, Зеленодольск муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиеш.

19. Зеленодол муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлегенең язма таләбе нигезендә, субсидияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле таләп алынганнан соң 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр билгеләнгән тәртиптә кире кайтарылырга тиеш.

20. Субсидияләр бирү шартларын, шулай ук төзелгән килешүләрнең үтәлешен тикшерүдә тоту Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлеге һәм «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет хакы»муниципаль учреждениесе тарафыннан башкарыла.

21. Оешмалар хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә оешмалар билгеләгән хезмәт хакын түләү срокларында акчалата түләүләр бирүне тәэмин итә.